КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 декабрь г.Казань № 1760

2024 елда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында «IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү үзәген булдыру чараларын тормышка ашыру турында

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указын тормышка ашыру, Россия Федерациясе стратегик үсешенең төп юнәлеше буенча проект комитеты утырышының 2018 елның 7 декабрендәге 3 номерлы беркетмәсе белән расланган «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешү максатларында, шулай ук 2023 – 2024 елларда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында «Балаларга цифрлы белем бирү үзәкләрен булдыру» чарасы буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирү өчен Россия Федерациясе субъектларын сайлап алуны үткәрү буенча Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы комиссиясе утырышының 2023 елның 14 августындагы ТВ-39/04пр номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында «IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү үзәген булдыру чараларын тормышка ашыру буенча төбәк координаторы итеп билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәген булдыру һәм аның эшчәнлеге буенча чаралар комплексын («юл картасын») расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 декабрь, 1760 нчы
карары белән расланды

«IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәген булдыру һәм аның эшчәнлеге буенча чаралар комплексы («юл картасы»)

| Т/с | Чараның исеме | Җаваплы | Нәтиҗәсе | Башкару срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Түбәндәгеләрне раслау:<br>«IT-кубы» үзәкләрен оештыру һәм эшләтү буенча чаралар комплексын («юл картасын»);<br>үзәкне төзү һәм эшләтү өчен җаваплыны;<br>Россия Федерациясе субъекты территориясендә «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәген төзү һәм эшләтү концепциясен, шул исәптән:<br>үзәкнең урнашу урынын (адресын, урыннар мәйданын, халык өчен транспорт белән бару мөмкинлеген);<br>«IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәге эшчәнлеге күрсәткечләре исемлеген;<br>үзәкнең белем бирү юнәлешләре исемлеген | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2023 елның 30 ноябреннән иртәрәк түгел |
| 2. | «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәген җиһазлау өчен җиһазлар, чыгым материаллары, укыту һәм тәрбия бирү чаралары исемлеген формалаштыру һәм раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Проект белән тәэмин итү үзәге | Проект белән тәэмин итү үзәге адресына хат;<br>Исемлекне килештерү турында Проект белән тәэмин итү үзәгенең хаты;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | федераль оператор тарафыннан җибәрелә торган график нигезендә |
| 3. | «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәгенең зоналаларга бүлү һәм дизайны проектын формалаштыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | «Мәгариф» илкүләм проектының белем бирү пространстволары бердәм концепциясе биналарының дизайны һәм зоналарга бүлү турында Проект | 2024 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | белән тәэмин итү үзәге адресына хат; дизайн һәм бүлмәләрне зоналаштыру проектына туры килүе турында бәяләмәсе белән Проект белән тәэмин итү үзәге хаты; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының бүлмәләрнең дизайн-проектын һәм зоналарга бүленешен раслау турында боерыгы | |
| 4. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген булдыру өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу игълан ителде | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Сатып алулар үткәрү турында хәбәр (Проект белән тәэмин итү үзәге формасы буенча) | 2024 елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча |
| 5. | «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәге төзелә торган мәгариф оешмасы турында мәгълүмати белешмә әзерләү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Проект белән тәэмин итү үзәге киңәш иткән форма буенча | 2024 елның 1 маеннан да соңга калмыйча |
| 6. | «IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү үзәгенең штат расписаниесен раслау (үзәк төзелгән оешманың штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы, базасында үзәк төзелгән оешманың локаль акты | 2024 елның 25 августыннан да соңга калмыйча |
| 7. | «IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү үзәген булдыру кысаларында матди кыйммәтләр һәм хезмәт күрсәтүләр кабул итүне раслый торган документлар реестрын төзү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы яки Проект белән тәэмин итү үзәге тарафыннан билгеләнә торган форма буенча | 2024 елның 25 августыннан да соңга калмыйча |
| 8. | «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәген бүлмәләрен Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының методик тәкъдимнамәләренә туры китерү буенча фотомониторинг үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы яки Проект белән тәэмин итү үзәге тарафыннан билгеләнә торган форма буенча | 2024 елның 25 августыннан да соңга калмыйча |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 9. | Үзәкнең балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлегенә лицензия алу (кирәк булганда) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министр-лыгы | Балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү про-граммаларын тормышка ашыруга лицензия | 2024 елның 25 августыннан да соңга калмыйча |
| 10. | «Мәгариф» илкүләм проекты, шул исәптән «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәге инфраструктурасына оештыру-методик ярдәм күрсәтү чараларының бердәм комплекслы планын формалаштыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министр-лыгы | Татарстан Респуб-ликасы Мәгариф һәм фән министр-лыгы боерыгы | 2024 елның 25 августыннан да соңга калмыйча |
| 11. | «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәге эшли башлау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министр-лыгы | Проект белән тәэмин итү үзәге киңәш иткән форма буенча | 2024 елның 15 сентябреннән дә соңга калмыйча |
| 12. | «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәге эшчәнлеге күрсәткечләренең үтәлүенә квартал саен мониторинг үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министр-лыгы | Федераль опера-торга күрсәткечләр мониторингы йомгаклары буенча хисап | 2024 елның 1 октябре, алга таба - квартал саен |
| 13. | «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәген укыту һәм тәрбия бирү чараларын файдаланып, мәгариф программаларын тормышка ашыручы педагогик хезмәт-кәрләрнең (федераль оператор реестрыннан программалар буенча) квалификациясен күтә-рүне үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министр-лыгы | Федераль оператор тәкъдим иткән форма буенча | 2024 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча |
| 14. | «IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәгенә җибәрелә торган җиһазлардан файдалану монито-рингын үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министр-лыгы, федераль оператор | Федераль оператор тәкъдим иткән форма буенча | 2024 ел дәвамында |